| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 2022 ел, 31 август | г.Казань | № 929 |

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының В.М. Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен һәм «Актүбә психо-неврология диспансеры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен «Актүбә психо-неврология диспансеры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауның дәүләт автоном учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан ш., Н.Ершов ур., 49 й. адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба - Республика клиник психиатрия хастаханәсе) һәм Азнакай районы, Актүбә штп., Лесная ур., 21б й. адресы буенча урнашкан: «Актүбә психоневрология диспансеры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба - Актүбә психоневрологик диспансер) Актүбә психоневрологик диспансерын Республика клиник психиатрия хастаханәсенә, Республика клиник психиатрия хастаханәсе исемен һәм эшчәнлегенең төп максатларын саклап калып, кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында дәкъдимен кабул итәргә.

2. Республика психиатрия хастаханәсе план биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү, шулай ук Республика психиатрия хастаханәсен үзгәртеп кору чараларын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында каралган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Республика психиатрия хастаханәсен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

законнар нигезендә үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

ел саен учреждение Уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә Республика психиатрия хастаханәсе өчен дәүләт йөкләмәсен расларга;

Республика клиник психиатрия хастаханәсе һәм Актүбә психоневрология диспансеры үзгәртеп корылганнан соң 30 көн эчендә Республика клиник психиатрия хастаханәсе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә һәм күзәтү советы составын расларга;

Уставка тиешле үзгәрешләр кертелгәннән һәм Республика психиатрия хастаханәсенең күзәтү советы составы расланганнан соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элегрәк Актүбә психонерология диспансеры оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт исемлеген (шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт) һәм күчемсез милек объектларына техник документацияне Республика психиатрия хастаханәсенә оператив идарә хокукында беркетү өчен тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

әлеге карарның 3 пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң 30 көн эчендә аны оператив идарә хокукында Республика психиатрия хастаханәсенә беркетергә;

Республика психиатрия хастаханәсенә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә милекне беркеткәннән соң 90 көн эчендә элек Актүбә психонерология диспансерының даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында булган җир кишәрлекләрен учреждениегә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин